ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур., 37в нчы йорт.
Тел.3-44-63

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423739, деревня Качкиново,
ул. Центральная,дом 37в,
Тел. 3-44-63

**05.11.2020г.** **№1**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлегенең Качкын һәм Усы авылларында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясына нигезләнеп Усы авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1.Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Усы авыл җирлеге террориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан тыш, җирле җыенда катнашуына һәм тавыш бирүдә катнашуларына бәйсез рәвештә,2021елда үзара салымның бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләвен кертергә һәм җыелган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
* **ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**
зиратларны чистарту, зиратлар территорияләрендә агачлар кисү, зиратларга керү юлларын ремонтлау;
* **җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
«Эреш» чишмәсе өстендә будка монтажлау, Үзәк урамы буенча урнашкан Усы авылы колонкасы өстендә будка монтажлау, Качкынавылында кое будкасын ремонтлау; Качкын авылында балалар мәйданчыгын монтажлау;
* **автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
Усы, Качкын авылларында тыкрыкларын ремонтлау (ком салу, грейдерлау), Качкын авылы Үзәк урамы буенча юл ремонтлау;
* **җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**
Усы авылында Үзәк урам буенча янгын гидранты урнаштырылган өстәмә колонканы монтажлау;
***җирлек чикләрендә халыкны электр белән тәэмин итүне оештыру:**
урам яктырткычларын ремонтлау һәм алыштыру.

“ӘЙЕ” «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Усы авылы , Яшьләр урамы, 5А йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Качкын авылы, Үзәк урамы, 37в йорт.;

4. Җыенны оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Усы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка җиткерергә.
6. Үтәлешне контрольдә тотам.

Усы авыл җирлеге башлыгы З.З.Әхмәев

ОГРН 1021605559051
Р 06-1038/09
Совет
УСИНСКОГО
сельского поселения
ИНН 1604002838